ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

22.01.2026 п.г.т. Алексеевское № 8-р

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм чаралары турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 20.10.2022 № 1122 карарына туры китереп,махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә ярдәм итү максатында

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләрнең һәм затларның, Татарстан Республикасында формалаштырылган «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнарның, махсус хәрби операциядә хәрби бурычларны үз теләге белән үтәүче гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) , Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы , Махсус хәрби операция уздыру зонасына җибәрелгән Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләренә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә (гаилә әгъзаларына) түбәндәге өстәмә ярдәм чаралары билгеләргә:

1.1. мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында баланы караган һәм карап торган өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү;

1.2. муниципаль мәгариф оешмаларында 1 - 11 сыйныфларда укучыларга ике тапкыр түләүсез кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) бирү;

1.3. өстәмә белем бирү, мәдәният учреждениеләрендә түгәрәк, секция, төркемле дәресләргә, төркемле экскурсияләргә йөргән өчен 18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларын түләүдән азат итү;

1.4. бассейнга, спорт (тренажер) залына, чаңгы базасына, спорт һәм яшьләр сәясәте учреждениеләренә барган һәм алардан файдаланган өчен 18 яшькә кадәрге балалар арасыннан гаилә әгъзаларын түләүдән азат итү;

1.5. Алексеевск муниципаль районы территориясендә урнашкан мәктәп яны лагерьларында, балаларны савыктыру лагерьларында каникул вакытында булган өчен ата-ана взносын түләүдән азат итү.

2. Әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән ярдәм чаралары махсус хәрби операциядә катнашкан гражданнарның балаларына кагыла.

3. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә яңа редакциядә өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибен расларга.

4. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 17.10.2022 ел, №122 р «Мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затларның гаиләләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» боерыгы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 26.12.2022 ел, № 144-р «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» боерыгы, үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе О. Н.Леденцовка йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгы** **С.А.Демидов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы Башлыгының
22.01.2026 № 8 - р
боерыгына кушымта

**Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе**
**(яңа редакциядә)**

1. Махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү тәртибе (алга таба – Тәртип) мәгариф оешмалары, өстәмә белем бирү, мәдәният, спорт һәм яшьләр сәясәте учреждениеләре тарафыннан өстәмә ярдәм чаралары күрсәтү механизмын билгели.

2.1. 1.1, 1.2, пунктлары буенча өстәмә ярдәм чаралары ата-ана (законлы вәкил) гаризасы нигезендә бирелә (форма бирелә).

Гаризага беркетелә:

- әлеге боерыкның 1 пунктында күрсәтелгән гаилә категориясен раслаучы документ (лар);

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (форма бирелә);

- бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (күчермә).

2.2. Мәгариф оешмасы җитәкчесе 1.1, 1.2 пунктлары һәм беркетелгән документлар буенча гариза алган көннән алып бер эш көне эчендә документларны карар кабул итү өчен «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ га тапшыра.

2.3.«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ гаризаны һәм беркетелгән документларны белем бирү оешмасы җитәкчесеннән алган көннән алып бер эш көне эчендә өстәмә ярдәм чаралары/бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм күрсәтмә акт чыгара. Социаль ярдәм чаралары гаризаны һәм беркетелгән документларны кабул итү датасыннан бирелә.

2.4. Социаль ярдәм чараларын күрсәтүдән баш тарту нигезе булып, булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган, аны алу хокукы булмау тора.

3.1. 1.3 пунктлар буенча өстәмә ярдәм чаралары ата-ананың (законлы вәкилнең) гаризасы нигезендә бирелә (форма кушымтада бирелә).

Гаризага беркетелә:

- күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гаилә категориясен раслаучы документ (лар);

- шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (форма бирелә);

- бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык (күчермә).

3.2.Өстәмә белем бирү, мәдәният учреждениесе җитәкчесе гариза һәм кертелә торган документлар алганнан соң бер көн эчендә өстәмә ярдәм чаралары бирү/өстәмә ярдәм чараларын бирүдән баш тарту турында карар кабул итә һәм күрсәтмә акты чыгара. Социаль ярдәм чаралары гаризаны һәм кертелә торган документларны кабул итү датасыннан бирелә.

3.3. Өстәмә ярдәм чараларын бирүдән баш тарту өчен нигез булып булган белешмәләр һәм документлар җыелмасы нигезендә ачыкланган аны алу хокукы булмау тора.

4. 1.4,1.5 пункты буенча өстәмә ярдәм чаралары күрсәтмәнең 1 пунктында күрсәтелгән гаилә категориясен раслаучы документ нигезендә бирелә.

**Советның**
**аппарат Җитәкчесе** **И.Ю. Монина**

*1.1,1.2 пунктлары өчен форма*

«Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ га

ГАРИЗА № ____

кемнән __________ 20__ г.

Мин ______________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы)

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |

теркәлгән адресы:

______________________________________________________________,
(телефоны, электрон почта адресы,индексы күрсәтелгән гариза бирүченең почта адресы)

СНИЛС (гаризачының) ___________________________.

Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы Башлыгының _________ № _______ боерыгы нигезендә,балага(балаларыма) социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләүне сорыйм,

______________________________________________________________:
( гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы) туган көне)

______________________________________________________________;
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

______________________________________________________________;
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

______________________________________________________________.
(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

Бала (балалар) мәгариф оешмасына теркәлгән

______________________________________________________________

______________________________________________________________
(мәгариф оешмасының исеме)

Социаль ярдәм чараларын күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга(на) риза

______________________________________________________________
(почта адресы буена, электрон почта адресы буенча )

Вакыт_____________ ______________________________
(гаризачы имзасы)

*1.3 пунтына форма*

Кая

______________________________________

______________________________________

*(өстәмә белем бирү, мәдәният учреждениесен күрсәтегез)*

ГАРИЗА № ____

көннән 20 г.

Мин______________________________________________________________,

(мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы)

| Шәхесне раслаучы документның исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирү вакыты |
|---|---|---|---|
| | | | |

теркәлгән адресы:

______________________________________________________________,

(телефоны, электрон почта адресы,индексы күрсәтелгән гариза бирүченең почта адресы)

СНИЛС (гаризачының) ____________________________.

Татарстан Республикасының Алексеевск муниципаль районы Башлыгының _________ № _______ боерыгы нигезендә,балага(балаларыма) социаль ярдәм күрсәтү чараларын билгеләүне сорыйм,

______________________________________________________________:

( гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы) туган көне)

______________________________________________________________;

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

______________________________________________________________;

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

______________________________________________________________.

(баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта соңгысы), туган көне)

Бала (балалар) мәгариф оешмасына теркәлгән

______________________________________________________________

______________________________________________________________

(мәгариф оешмасының исеме)

Социаль ярдәм чараларын күрсәтү (бирүдән баш тарту) турында мәгълүмат алуга(на) риза

______________________________________________________________

(почта адресы буена, электрон почта адресы буенча )

Вакыт______________ ______________________

(гаризачы имзасы)

*Форма*

Шәхси мәгълүматны эшкәртү ризалыгы

Мин,______________________________________________________________________________,

*(Ф. И. А. (соңгысы улганда)тулысынча)*

_______________________________________________________________________________

*(контакт мәгълүматы: телефон номеры, электрон почта адресы яки шәхси мәгълүмат субъектының почта адресы)*

Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданинның баласына (балаларына) социаль ярдәм чараларын билгеләү максатларында «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге» МКУ га автоматлаштыру чараларын кулланып яисә андый чараларны кулланмыйча башкарыла торган (теләсә нинди гамәл (операция) яисә җыелма гамәлләр (операцияләр), шул исәптән җыю, язу, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү) өчен ризалык бирәм, чыгару, куллану, тапшыру (тарату, тәэмин итү, керү), минем шәхси мәгълүматларымны (белешмәләрне)йөзсезләү, блоклау, бетерү, юк итү һәм балигъ булмаган балаларымның шәхси мәгълүматларын (белешмәләрен)

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

*(Ф. И. А. (соңгысы булганда), туган көне)*

_______________________________________________________________________________

_______________________________________________________________________________

фамилиясе, исеме, атасының исеме; туган көне; гаилә хәле; паспорт мәгълүматлары; теркәлү һәм яшәү урыны адресы; элемтә өчен телефон номеры.

Балигъ булмаган балалар турында шәхси мәгълүматларны, белешмәләрне эшкәртүгә әлеге ризалык архив законнарында билгеләнгән срогы чыкканчы, социаль ярдәм чаралары күрсәтүгә документлар саклау өчен гамәлдә.

_______________________________________________________________________________

*(вакыт)* *(фамилиясе, исеме, атасының исеме) (соңгысы булганда)* *(имза)*